Күңел лирикасының гаҗәеп камил үрнәкләреннән булган “Урман кызы” шигъри текстын Һ.Такташ Ташкент шәһәрендә яшәгән Әминә исемле туташка багышлап яза. Беренче строфада лирик герой сөйгән кызы сурәтенә салып ярату хисенең эчтәлеген сөйләп бирә. Яшьлек, матурлык, чисталык символы гөл һәм күкләргә бәйле җанны символлаштырган күбәләк образларының янәшә килүе мәхәббәт хисенең күңелне илаһи белән тоташтыручы күпер икәнлеген әйтә. Символик укылышта сынаулар аша үтү юлы кебек шәрехләнгән “шаулап торган киң карурман” дип тәкъдим ителгән пространствода кара шәл ябынган матур кыз бирелеше текстта чит / үз бинар оппозициясенең оешуын билгели. Шәл / яулык халык авыз иҗатында ике чик (читнеке һәм үз, якын, кадерле) арасында торучы деталь буларак укыла. Матурлык, ярату символы кызның (“гөлдән үреп муенсалар тагынган”) кара шәл ябынуы күңел хисләрен, ягъни күкләргә бәйле хасиятне – илаһи сафлыкны саклау теләге ул. Димәк, беренче строфада ук кешенең табигый халәте – яратырга теләве үзендәге илаһи сафлыкны сакларга омтылышы дип шәрехләнә. Лирик геройның Әминәгә үз итеп, сак кына сеңлем дип эндәшүе дә автор тарафыннан төгәл уйланылган. Лирик геройның даими халәте – илаһи сафлыкны тоюдан туган тиңсез бәхет, серле-сихри сөенеч.

Икенче строфада пространство “ил”, “ялан” дип үзгәртелә. Лирик герой өчен ярату халәте – тормышның үзе, чыны (“Син бер хәят үзең”). Шул урында кертелгән толым детале текстта гел кабатлана. Күп мәдәниятләрдә яшәү көчен символлаштырган образга Һ.Такташ ярату көчен белдерү мәгънәсен өсти. Хәят, ягъни бәхет толымнарга кул сузу – ярату биргән көчне тоя алуда.

Лирик геройның бәхетле булу теләге өченче строфада хиснең көчәйтелүе аша әйтелә (“Тарат, сеңлем, озын чәчләреңне”). Матурлыкның яшәү символы – су белән бәйле аталышы да очраклы түгел. Су кызы – һәр кеше тоярга тиешле бәхет халәтенең аталышы ул (“Узган-барган кешеләр туктап карап, Су кызы дип сине уйласын!”). Лирик герой биредә яратуга мәкер, шөбһә белән караганнарга мөнәсәбәтен белдерә, гаепләми ләкин, бары юл күрсәтә. Автор илаһи сафлыкны югалтканнарга түгел, ә ярату хисе белән “дуслашырга” теләгәннәргә “урман углы” мифологик детале аша мөрәҗәгать итә. Һ. Такташның көтелгән укучысы – үзендәге сафлыкны сагынган, сынаулардан торган чынбарлыкта җанына тынгылык тапмаган, берөзлексез нидер эзләүче, “көтүче” (“Ник булмадым мин бер урман углы – Синең дустың — яшь бер көтүче?”).

Алдагы строфада сөйләнгән мәхәббәт тарихы лирик герой кичерешләренең кабатлануы һәм гомумиләштерелүе генә түгел. Бу өлеш – Һ.Такташның татар укучысына текстны төрле мәдәниятләр контектында укырга чакыруы.

Икенче бәйләмне кабатлап килгән бишенче строфада мәдәниятләрнең янәшәлеге аша яратуга бәйле яшәеш юлы раслана. Кызның матурлыкны сер итеп саклавы лирик геройны бәхетле хәяттә – ярату халәтендә яшәтүче бердәнбер көч. Димәк, яратуның ныклыгы – аны сер итеп саклый белүдә. Лирик герой бәхетле яшәү юлын тапкан, ул хәзер саксыз кагылмас, рәнҗетмәс, мәкерле була алмас. Сер аны гел үзенә дәшәр, уйланырга (кайчак борчылырга, ашкынырга, ә кайчак бары сөенергә) чакырыр.

Биредә толым детален күңел һәм мәңгелекне символлаштыручы шаян күзләр образы алыштыра. Димәк, мәңге яшәү илаһи сафлыкны саклый белүгә, сер көченә бәйле. Күз аерым мәдәниятләрдә белемне дә белдереп килә. Димәк, белемгә омтылыш мәңгелекнең бер чагылышы буларак илаһи серне үзеңдә йөртүгә бәйле.

Нигә?.. Нигә синең шаян күзләр
Күзләремә болай багалар?
Нинди көчләр, сөйлә, нинди көчләр
Керфек очларыңнан агалар?!

Алтынчы, җиденче, сигезенче бәйләмнәрдә яратуның даими халәт, мәңгелекне тоюга алып килергә сәләтле икәнлеге раслана. Кайгы-хәсрәттән торган “карурманны” бакча итәр көч бар, ди автор. Шул көч син табарга тиешле җәүһәрне эзләтә, гамь, рух, бирә, дөньяга килүне аклый.

Беләм, мине көткән кайгы-хәсрәт

Тау-тау булып анда өелгән;

Беләм, шул тауларның асларында

Мин эзләгән җәүһәр күмелгән.

Гөлфия Гайнуллина